КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 27 ноябрь г.Казань № б-2637

Мәгариф, мәдәният, гражданнарның сәламәтлеген саклау, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын яхшырту, шулай ук «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлекне саклау һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге 256-ФЗ номерлы, «Мәдәният, сәламәтлекне саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар һәм тарафыннан медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 5 декабрендәге 392-ФЗ номерлы федераль законнарны гамәлгә ашыру максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2027 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасында мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлекне саклау һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру буенча чаралар планын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 14 декабрь, б-2742 нче боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу боерык 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 27 ноябрь, б-2637 нче
боерыгы белән расланды

## 2027 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасында мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлекне саклау һәм мәгариф өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру буенча чаралар планы

| Т/с | Чараның исеме | Гамәлгә ашыру формасы | Үтәү срогы | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Мәдәният, сәламәтлекне саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар (алга таба – оешмалар) тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет булдыруны башлап җибәрү | оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет булдыру турындагы тәкъдим белән Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, муниципаль районның (шәһәр округының) иҗтимагый советына мөрәҗәгать | өч елга бер тапкыр, әмма план елына кадәрге елның 25 ноябреннән дә соңга калмыйча | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – вәкаләтле органнар), муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 2. | Оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет составын раслау | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, муниципаль районның (шәһәр округының) иҗтимагый советы карары | өч елга бер тапкыр, әмма әлеге Планның 1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать алынган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы (килешү буенча), муниципаль районнарның (шәһәр округларының) иҗтимагый советлары (килешү буенча) |
| 3. | www.bus.gov.ru адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт (муниципаль) учреждениеләре турында мәгълүмат | мәгълүматны урнаштыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны һәм турыдан-туры башкаручыларны билгеләү турында хокукый акт | даими | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | урнаштыру өчен рәсми сайтта (алга таба – www.bus.gov.ru рәсми сайты), вәкаләтле органнарның, муниципаль районнардагы (шәһәр округларындагы җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүматның дөреслеген, тулылыгын һәм аны үз вакытында урнаштыруны тәэмин итү, шулай ук гражданнар тарафыннан рәсми сайтка керүләр һәм аларның бәяләмәләренә мониторинг алып бару, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү эшен оештыру һәм рәсми сайтында кабул ителгән чаралар турында гражданнарга хәбәр итү | | | |
| 4. | Вәкаләтле органнарның, муниципаль районнардагы (шәһәр округларындагы) җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтларында хезмәт күрсәтелүчеләрнең хезмәтләр күрсәтү шартлары турында фикерен белдерү өчен техник мөмкинлекләр тәэмин итү | күрсәтелгән хезмәтләрнең сыйфаты турында гражданнарның фикерләрен анализлау максаты белән хезмәт күрсәтелүчәрдән интернет сораштыру өчен вәкаләтле органнарның, муниципаль районнардагы (шәһәр округларындагы) җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның рәсми сайтларында урнаштырылган интерактив анкета | даими | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 5. | Планлаштырыла торган елга оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү уздырыла торган оешмалар исемлеген төзү | хезмәтләр күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советның оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү планлаштырыла торган оешмалар исемлеген раслау турында карары | план елына кадәрге елның декабре | хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советлар (килешү буенча) |
| 6. | Эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу | эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу | план елының гыйнва- | хезмәтләр күрсәтү шартлары сый- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | турында документация проектларын, оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат җыюны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыручы оешма (алга таба – оператор оешма) белән вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган дәүләт дәүләт контрактлары, муниципаль контрактлар проектларын карап тикшерүдә катнашу | турындагы документлар эчтәлеге буенча тәкъдимнәр | ры | фатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советлар (килешү буенча) |
| 7. | Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарда билгеләнгән оператор оешманы билгеләү процедураларын үткәрү | конкурс процедуралары ярдәмендә оператор оешманы билгеләү | план елының гыйнвары | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 8. | Оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү турында халыкка, җәмгатьчелек һәм һөнәри берлек вәкилләренә мәгълүмат бирү өчен халык алдында чаралар үткәрү, әлеге мәсьәлә буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек итү | чаралар уздыру планы һәм аны гамәлгә ашыру турында хисап | планны раслау – агымдагы елның гыйнвары, гамәлгә ашыру турында хисап – план сроклары нигезендә | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 9. | Оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүматны җыю һәм гомумиләштерү буенча башкарылган эшләр турында хисап эшләү һәм аны хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советка җибәрү | хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советка җибәрелгән оператор оешмасының хисабы | оператор оешмадан хисап алганнан соң 10 эш көне эчендә, әмма 30 октябрьдән дә соңга калмыйча (ел саен) | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 10. | Оператор оешманың хисабы нигезендә хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен төзү, аларның эшчәнлеген яхшырту буенча | вәкаләтле органга, муниципаль районның (шәһәр округының) җирле үзидарә органына җибәрелгән хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфа- | оператор оешманың хисабын алган көннән соң бер ай эчендә, әмма 30 ноябрьдән дә | хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советлар (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | тәкъдимнәр эшләү | тын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары | соңга калмыйча (ел саен) | |
| 11. | Хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен түбәндәгеләргә җиткерү:<br>хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү уздырылган оешмалар җитәкчеләренә;<br>оешмалар өчен җавап биргән вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары | хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары | хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый совет карары алынган көннән бер ай эчендә, әмма агымдагы елның ноябреннән – декабреннән дә соңга калмыйча | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 12. | Оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча оешмаларның планнарын (алга таба – җитешсезлекләрне бетерү планы) әзерләү һәм раслау | җитешсезлекләрне бетерү планын раслау турында хокукый акт | хисап елыннан соң килә торган елның беренче кварталы дәвамында | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 13. | Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында, «Интернет» челтәрендә бәйсез бәяләү буенча иҗтимагый советлар эшчәнлеге турында мәгълүмат урнаштыру:<br>Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2019 елның 7 маендагы 66н номерлы боерыгы нигезендә www.bus.gov.ru рәсми сайтында;<br>вәкаләтле органнарның, муниципаль районнардагы (шәһәр округларындагы) җирле үзидарә органнарының рәсми | вәкаләтле органнарның, муниципаль районнардагы (шәһәр округларындагы) җирле үзидарә органнарының рәсми сайтында, www.bus.gov.ru рәсми сайтында мәгълүмат;<br>җитешсезлекләрне бетерү планнары | хисап елының 1 декабренә кадәр (ел саен)<br>хисап аеннан соң килә торган айның 10 апреленә кадәр | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | сайтларында | | | |
| 14. | Җитешсезлекләрне бетерү планнарының үтәлешен контрольдә тоту | җитешсезлекләрне бетерү планнарын үтәү турында оешмаларның хисаплары | җитешсезлекләрне бетерү планында билгеләнгән срокларда | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 15. | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм Татарстан Республикасы гамәлгә куючы булган мәдәният, сәламәтлекне саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендәге оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшчәнлеге нәтиҗәләре турында еллык хисапка кертү өчен әлеге оешмалар эшчәнлеген камилләштерү буенча күрелә торган чаралар турында белешмә әзерләү | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына тапшыру өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерелгән мәгълүмат | хисап елыннан соң килә торган елның 15 февраленә кадәр | вәкаләтле органнар, муниципаль районнарның (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 16. | вәкаләтле органнар, муниципаль районнардагы (шәһәр округларындагы) җирле үзидарә органнар тарафыннан үзләренең рәсми сайтларында һәм www.bus.gov.ru рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүмат буенча вәкаләтле органнар, муниципаль районнардагы (шәһәр округларындагы) җирле үзидарә органнар тарафыннан Татарстан Республикасында мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлекне саклау һәм мәгариф өлкәсендәге оешмаларның хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне гамәлгә ашыруга мониторинг ясау | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына тапшыру өчен мәгълүмат | 5 мартка кадәр (ел саен) | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе |

---